ГЛАВА
МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с.Верх.Тат.Майна КАРАР

12.11.2021 № 12

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Горка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» Майна авыл җирлеге башлыгы карарын гамәлдән чыгару хакында**

«Татарстан Республикасында яңа коронавируслы инфекция таралуны булдырмау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 1006 номерлы ТР МК карарын исәпкә алып, яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Горка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 03 ноябрендәге 8 номерлы Майна авыл җирлеге башлыгы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Майна авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**